РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2019 Олы Кайбыч авылы № 02

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын реализацияләү урыннары оештыру турында**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын контрольсез кертү һәм реализацияләүне булдырмау максатында

**КАРАР ИТӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм тере йорт кошларын реализцияләү урыны итеп Кайбыч районы Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 22/1нче йорт адресы буенча якшәмбе ярминкәсе үтә торган урынны билгеләргә.

2. Кайбыч муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү , ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгы белән тәэмин итү комиссиясенә квартал саен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясенә авыл хуҗалыгы терлекләре һәм кошлары белән керергә мөмкин булган йогышлы чирләр профилактикасы мәсьәләләре буенча көн тәртибенә йогышлы чирләрне кертү һәм таратуны булдырмау буенча җаваплы кешеләрне тыңлау да кертелгән киңәшмәләр уздырырга.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- участок полиция вәкилләре белән берлектә үз территорияләрендә авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын контрольсез кертү һәм реализацияләүне булдырмау максатында контрольне көчәйтергә;

- районда авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын контрольсез кертү һәм реализацияләүнең куркынычлыгын аңлату максатында дәүләт ветеринар хезмәте белгечләре катнашында авыл җирлекләре халык җыеннары үткәрергә.

4. Россиянең Татарстан Республикасы Кайбыч районы буенча ЭЭМБнә ТР ДВИ Апас территориаль бүлекчәсе белән берлектә дәүләт ветеринар күзәтүе контроле үтәргә тиешле тыелган ташуларны һәм авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын контрольсез кертү һәм реализацияләүне кисәтү максатында чаралар уздырырга (район территориясендә ТР Кайбыч муниципаль районы ЭЭМБнең ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре һәм дәүләт ветеринар инспекциясе яисә РФнең ТР буенча Россельхознадзор хезмәткәрләре катнашында күчеп йөрүче дежур мобиль төркем эшен оештыру юлы белән) .

5. «Кайбыч РДВБ» ДБУнә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә :

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә алда әйтелгән йөкләр ачыкланган очракта аларны вакытлыча изоляциялəп саклау, хайваннарны вакытлыча тоту (карантин үткәрү) өчен урын билгеләргә һәм җиһазларга;

- авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларын контрольсез кертү һәм реализацияләүнең куркынычлыгын төшендерү максатында халык белән вакытлы матбугат һәм басма продукция аркылы аңлату эшләре үткәрергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы урынбасары Р.Р.Хәялиевка йөкләргә.

**А.И.Рәхмәтуллин**